КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 03 октябрь г.Казань № 1218

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 декабрь, 997 нче; 2015 ел, 17 апрель, 260 нчы; 2015 ел, 9 сентябрь, 659 нчы; 2015 ел, 8 октябрь, 753 нче; 2016 ел, 14 март, 139 нчы; 2016 ел, 26 октябрь, 785 нче; 2017 ел, 8 май, 264 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 763 нче; 2017 ел, 20 октябрь, 799 нчы; 2018 ел, 4 май, 316 нчы; 2018 ел, 8 август, 647 нче; 2019 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы; 2019 ел, 15 апрель, 291 нче; 2019 ел, 13 июль, 575 нче, 2019 ел, 15 ноябрь, 1042 нче, 2020 ел, 22 гыйнвар, 16 нчы, 2020 ел, 22 июнь, 511 нче, 2020 ел, 22 август, 722 нче, 2020 ел, 03 сентябрь, 780 нче, 2021 ел, 4 март, 117 нче, 2021 ел, 30 июнь, 524 нче, 2021 ел, 16 август, 722 нче, 2022 ед, 4 июнь, 520 нче, 2023 ел, 23 гыйнвар, 34 нче, 2023 ел, 24 апрель, 516 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба - дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктта:

«чираттагы финанс елына» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

«Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары һәм актларныңаерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 3 октябрь, 1218 нче
карары редакциясендә)

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

## «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

### I. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт өлкәсендә агымдагы халәтне бәяләү

Дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәле системасы дәүләтнең динамик үсешенең мөһим шарты булып тора.

Бүген Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында заманча таләпләргә туры килә торган һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрү максатларында хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән бердәм кадрлар сәясәте төзелгән.

Татарстан Республикасы Президентының «2010 - 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү программасын раслау турында» 2010 елның 23 августындагы ПУ-552 номерлы Указы белән расланган 2010 - 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 декабрь, 910 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы тулы күләмдә гамәлгә ашырылган.

Гамәлгә ашырыла торган программа чаралары дәүләт һәм муниципаль хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба - дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр) һөнәри үсеше мәсьәләләрен хәл итәргә мөмкинлек бирде.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәле кадрлар составын формалаштыру Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган кадрлар сәясәтенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора. Хәзерге вакытта федераль законнар нигезендә

дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар потенциалын сайлап алу һәм комплекслы бәяләү, идарәче кадрларны бәяләү системасы эшли, гади һәм идарә итү вазифаларын югары квалификацияле кадрлар белән оператив рәвештә биләргә мөмкинлек бирә торган кадрлар резервын формалаштыру системасы гамәлгә кертелгән. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга бердәм тест кертелде, республика дәүләт органнарында конкурс һәм аттестация комиссияләре эшчәнлеген үзәкләштерелгән координацияләү тәэмин ителде.

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне әзерләүнең комплекслы системасы формалаштырылган һәм эшли, ул хезмәткәрләрнең барлык категорияләрен дә колачлый һәм аларның һөнәри үсешенең өзлексез булуын тәэмин итә. Белем бирү процессына белем бирүнең заманча технологияләрен кертү буенча даими эш алып барыла, мобиль мәгълүмат-белем бирү платформасы эшләнде һәм кулланыла.

Профессиональ үсештә басым укытуның гамәли юнәлешле формаларына ясала. Республика башкарма хакимият органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә эчке стажировка мәйданчыклары системасы булдырылды.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъектларының уңышлы тәҗрибәләрен һәм алдынгы тәҗрибәсен өйрәнүне көчәйтергә кирәк. Ислам хезмәттәшлеге оешмасы әгъзалары булган илләр белән кадрлар әзерләү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек урнаштыру мөһим.

Хезмәткәрләрне укытуда цифрлы, мәгълүмати-аналитик, тел һәм коммуникатив күнекмәләр дәрәҗәсен арттыру мәсьәләләренә игътибар бирелә. Шул ук вакытта хәзерге шартларда дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрдә хезмәт кыйммәтләрен, бирелгәнлекне, патриотизмны, җитәкче составта - лидерлыкны, системалы һәм стратегик фикерләүне үстерү зарур. Шулай ук хезмәткәрләр компетенцияләренә даими рәвештә үсә торган таләпләрне һәм югары хезмәт йөкләнешен исәпкә алып, һөнәри үсеш чараларына аерым игътибарны сәламәтлекне саклау, стресс белән идарә итү, һөнәри янгынны профилактикалау кебек мәсьәләләргә бирергә кирәк.

Җирле үзидарә органнарының кадрлар составын укытуның формалаштырылган системасы кысаларында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре, авыл җирлекләре башлыклары, авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары һәм башка категорияләр өчен махсус укыту программалары циклы гамәлгә ашырыла. Муниципаль кадрларның квалификациясен һәм һөнәри әзерлек дәрәҗәсен даими нигездә күтәрү мөһим.

Россия Федерациясе законнары, дәүләт һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы законнары үтәлешен даими мониторинглау нигезендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын актуальләштерү һәм камилләштерү буенча системалы эш башкарыла.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтнең ачыклыгын һәм җәмәгать контроленнән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы хакимият органнарының рәсми сайтларында, дәүләт хезмәтенең федераль порталында вакантлы вазыйфалар турында, дәүләт һәм муниципаль хезмәткә керү

тәртибе турында, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше турында актуаль мәгълүмат урнаштырыла.

Хәзерге вакытта дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүнең бердәм системасы эшли, хезмәткәрләрне бүләкләү, матди ярдәм күрсәтү һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына өстәмә билгеләү тәртибе билгеләнгән. Дәүләт хезмәткәрләрен мотивацияләү системасын камилләштерү максатларында ел саен дәүләт хезмәткәрләре хөрмәтенә электрон такта төзелә, «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы уздырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль идарә системасында мәгълүмати технологияләрне гамәлгә кертү һәм куллану исәбенә кадрлар эшенең нәтиҗәлелеген камилләштерүгә һәм арттыруга аерым игътибар бирелә. 2013 елда башланган кадрлар эшен цифрлаштыру проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә хәзерге вакытка персонал белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмати киңлек формалаштырылды, аның һәр элементы кадрлар эшенең гомуми процессына үрелгән. Мәгълүмат киңлегенең үзәк звеносы булып «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба - Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы) тора, ул кадрлар эшенең бердәм стандартларын кертүгә, кадрлар процессларын оптимальләштерү исәбенә дәүләт һәм муниципаль хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итте.

Бердәм мәгълүмати кадрлар системасын башка мәгълүмат системалары белән интеграцияләү буенча эшләр башкарылды:

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән;

«Татарстан Республикасында электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы» дәүләт мәгълүмат системасы белән;

«Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплары» дәүләт мәгълүмат системасы белән;

«БК белешмәләре» махсус программа тәэмин ителеше белән.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәткә яшь белгечләрне җәлеп итү, аларны тиз яраклаштыру, коллективларның бердәмлеген арттыру һәм белем бирү программаларын оештыру максатларында «PROслужбу. Татарстан» сыйфатлы башка дәрәҗәдә мобиль кушымта эшләнде һәм гамәлгә кертелде . Кушымтаның функционалы ярдәмендә хезмәткәрләрнең формалашкан белем базасына даими керү мөмкинлеге бар, дәүләт хезмәтенә керергә теләүче гражданнарның хакимият органнарында теләсә нинди вакансиягә җавап бирү һәм электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге бар.

Республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәттә хезмәт культурасын үстерү проекты гамәлгә ашырыла. Әлеге юнәлештә эшне оештырганда гамәли җитәкчелек өчен «Татарстан Республикасы хакимият органнарының хезмәт культурасы» дигән махсус методик пособие эшләнде, уңай социаль-психологик климатка ярдәм итү чаралары уздырыла, төп белем бирү программалары кысаларында хезмәт культурасы буенча махсус укыту модуле кертелде.

Кадрлар эшен тәэмин иткәндә һәм программа чараларын гамәлгә ашырганда дәүләт һәм муниципаль хезмәттә коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтне оештырганда бердәм алымнар тәэмин ителә, Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында һәм шәһәр округында муниципаль хезмәтне үстерү муниципаль программалары кабул ителде.

Тулаем алганда, Татарстан Республикасында соңгы 10 елда кадрлар, аларны саклау һәм эшкәртү, персоналны сайлап алу һәм бәяләү, адаптацияләүне, һөнәри үсешне һәм мотивацияләүне оештыру, шулай ук кадрлар эшен алып бару һәм системалаштыру ысуллары шактый үзгәртелде.

Барлык санап үтелгән чаралар дәүләт һәм муниципаль хезмәттә кадрлар составын көчәйтергә, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга һәм, нәтиҗә буларак, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен алга таба да нәтиҗәле үтәүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

## II. Дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең өстенлекләрен һәм максатларын тасвирлау

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба - Татарстан Республикасы дәүләт программасы) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне (алга таба - дәүләт һәм муниципаль хезмәт) үстерүгә юнәлтелгән.

Татарстан Республикасы дәүләт программасының өстенлекләре «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Стратегия-2030) белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба - Стратегия-2030) «2021 - 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте үсешенең төп юнәлешләре турында» 2021 елның 21 маендагы ПУ-398 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына туры килә.

Татарстан Республикасының стратегик максатларына һәм социаль-икътисадый үсеш бурычларына ирешү өчен максатлар һәм бурычлар билгеләнде, Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренең структурасы һәм системасы эшләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары:

Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү.

## III. Стратегия-2030 ның стратегик өстенлекләре, милли максатлары һәм максатлары белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Кеше капиталын үстерү, икътисадта кеше капиталына ихтыяҗ булган һәм уңышлы эшли ала торган иҗтимагый институтлар булдыру, кеше - талантлар йөртүче - гамәлгә ашырылырга мөмкин булган шартлар - Стратегия-2030 өстенлекләре.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы чаралары дәүләт һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар потенциалын арттыруга, дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында мотивлаштырылган һәм квалификацияле хезмәткәрләрне беркетүгә, талантлы, инициативалы хезмәткәрләрне ачыклауга һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Заманча технологияләрне кадрлар эшенә, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен гамәлгә кертү «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсеше милли максатлары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән каралган «Цифрлы трансформация» милли максаты кысаларында дәүләт идарәсенең «цифрлы өлгергәнлегенә» ирешүгә ярдәм итә.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясын һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 44 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү юнәлешләрен билгели.

## IV. Дәүләт идарәсе бурычлары, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү өлкәсендә аларның нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

1. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген (шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша) күтәрү.

2. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, аларның эшчәнлеген комплекслы бәяләүнең һәм аларны хезмәт буенча үстерүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициативалы хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү.

3. Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы циклдагы белем бирү мохитен булдыру.

4. Дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү.

5. Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының хезмәт культурасын камилләштерү, дәүләт һәм муниципаль хезмәт системасында лидерлыкны һәм патриотизмны үстерү.

6. Һөнәри мотивлаштырылган яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәтнең абруен арттыру, уңайлы шартлар тудыру.

7. Җәмәгать контроле системасын һәм граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүне үстерү, дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору буенча чараларны гамәлгә ашыру.

8. Дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне норматив һәм методик тәэмин итү.

9. Дәүләт хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмати-коммуникация технологияләрен куллану.

## «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы паспорты

### 1. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы кураторы | Сәфәров Әсгать Әхмәт улы – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры | I этап: 2014 – 2023 еллар;<br>II этап: 2024 – 2026 еллар |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары | 1. Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү |
| Гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанс белән тәэмин итү күләмнәре | I этап: 375 317,08 мең сум;<br>II этап: 106 755,0 мең сум |
| Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары, 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең (алга таба – Стратегия-2030), Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары белән бәйләнеш | Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру «Кеше капиталы» Татарстан Республикасы стратегик максатларының берсенә ирешүгә юнәлдерелгән.<br>«Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы |

## 2. Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Арту / кимү билгесе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификациясе буенча) | База күрсәткече | | Еллар буенча күрсәткеч әһәмияте | | | Документ | Күрсәткечкә ирешү өчен җаваплы | Илкүләм максатлар, Стратегия-2030 максатлары күрсәткечләре белән бәйләнеш | Муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә ашырыла торган билге | Мәгълүмат системасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәткече | елы | 2024 | 2025 | 2026 | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре турында ел саен актуальләштерелгән хокукый актлары булу | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | - | юк | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары |
| 2. | Кадрлар эше нәтиҗәлелеген квартал саен мониторинглау нигезендә дәүләт органнарының һәм җир- | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында му- | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү | - | әйе | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ле үзидарә органнарының формалаштырылган рейтингы | | | | | | | | | ниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | буенча), дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | | | |
| 3. | Дәүләт органнарында структур бүлекчәләр җитәкчеләренең гомуми санында дәүләт органнарында кадрлар резервы төзелгән (актуальләштерелгән) структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 95 | 2023 | 95 | 95 | 95 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | дәүләт органнары | - | юк | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы |
| 4. | Идарә кадрлары резервына кертелгән затлар саны | ДП | арта бара торган | кеше | 15 | 2023 | 15 | 0 | 15 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча) | - | юк | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Һөнәри үсеш чараларында (өстәмә һөнәри белем бирүне кертеп) катнашучы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, җәмәгать судлары аппаратлары хезмәткәрләре өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 33 | 2023 | 33 | 33 | 33 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | - | әйе | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы |
| 6. | Гавами хакимият органнарының төп игътибарны клиентларга бирүенә, дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләр-нең цифрлы, мәгълүмат-аналитика һәм коммуникатив күнек- | ДП | арта бара торган | процент | 60 | 2023 | 65 | 70 | 75 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан | - | әйе | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәләре дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән компетенцияләрне үстерү блокларын үз эченә алган, гамәлгә ашырылган мәгариф программалары өлеше | | | | | | | | | 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | | | |
| 7. | «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» конкурсын үткәрү | ДП | арта бара торган | берәмлек | 1 | 2023 | 0 | 1 | 0 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе (килешү буенча), дәүләт органнары | - | юк | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты мәгълүматлары |
| 8. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эшләнгән Электрон мактау тактасы | ДП | арта бара торган | берәмлек | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча), дәүләт органнары | - | юк | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | | | | департаменты мәгълүматлары |
| 9. | Дәүләт органнарының гомуми санында һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә студентларны практикага (стажировкага) алган дәүләт органнары өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча) | - | юк | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты мәгълүматлары |
| 10. | Яшьләр өчен дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсе, халыкның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегеннән канәгатьлелеге, шулай | ДП | арта бара торган | берәмлек | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | - | юк | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ук дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеге һәм абруе турында материаллар бирелгән статистика җыентыклары саны | | | | | | | | | | | | | |
| 11. | Социаль челтәрләрдә һәм башка заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларында урнаштырылган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне популярлаштыруга һәм аларның абруен күтәрүгә юнәлдерелгән материаллар саны | ДП | арта бара торган | берәмлек | 15 | 2023 | 20 | 20 | 20 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе (килешү буенча) | - | юк | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәгълүматлары |
| 12. | Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт өлкәсендә | ДП | арта бара торган | берәмлек | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | - | юк | Татарстан Республикасы Юстиция мини- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | законнарга үзгәрешләр кертү турында еллык хисап | | | | | | | | | дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | | | | стрлыгы мәгъ-лүмат-лары |
| 13. | Дәүләт граж-дан хезмәте һәм муници-паль хезмәт турындагы законнарны үтәү, дәүләт органнарын-да һәм җирле үзидарә органнарын-да кадрлар эшен камил-ләштерү, персонал белән идарә итүнең заманча тех-нологиялә-ренә ориен-тацияләү буенча тик-шерү чара-лары саны | ДП | арта бара торган | берәм-лек | 8 | 2023 | 8 | 8 | 8 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе (килешү буенча) | - | юк | Татар-стан Респуб-ликасы Рәисе кар-шын-дагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департа-менты мәгъ-лүмат-лары |
| 14. | Бердәм мәгъ-лүмат кадр-лар систе-масында, техник биремдә күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып, | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълү-мат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, | - | юк | Татар-стан Респуб-ликасы Дәүләт идарә-сен цифрлы нигездә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | функционал артуга бәйле рәвештә кертелгән үзгәрешләр булу | | | | | | | | | Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча) | | | үстерү, мәгъ-лүмат техноло-гияләре һәм элемтә министр лыгы мәгъ-лүмат-лары |
| 15. | Бердәм мәгъ-лүмат кадрлар системасында дәүләт органнарыны ң һәм җирле үзидарә органнарыны ң кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълү-матлар булу | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча) | - | әйе | Бердәм мәгъ-лүмат кадрлар система-сы |
| 16. | Муниципаль берәмлекләр-нең гомуми санында дәүләт про-граммасында билгеләнгән чорга муни-ципаль хез-мәтне үстерү буенча муни-ципаль пр-ограммалар расланган муниципаль | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | - | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | - | әйе | Татарста н Республи касы Юстиция министр лыгы мәгъ-лүмат-лары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | берәмлекләр өлеше | | | | | | | | | 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары | | | | |

## 3. 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешү планы

| Т/с | Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары/күрсәткечләре | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификациясе буенча) | Айлар буенча план күрсәткечләре | | | | | | | | | | | 2024 ел ахырына |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гыйнвар | февраль | март | апрель | май | июнь | июль | август | сентябрь | октябрь | ноябрь | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 1. | Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре турында ел саен актуальләштерелгән хокукый актлары булу | ДП | процент | 5 | 10 | 15 | 20 | 30 | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | 100 |
| 1.2. | Кадрлар эше нәтиҗәлелеген квартал саен мониторинглау нигезендә дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының формалаштырылган рейтингы | ДП | берәмлек | - | - | 100 | - | - | 100 | - | - | 100 | - | 100 | 100 |
| 1.3. | Дәүләт органнарында структур бүлекчәләр җитәкчеләренең гомуми санында дәүләт органнарында кадрлар резервы төзелгән (актуальләштерелгән) структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары өлеше | ДП | процент | 0 | 5 | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | 95 |
| 1.4. | Идарә кадрлары резервына кертелгән затлар саны | ДП | кеше | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 15 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 15 |
| 1.5. | Һөнәри үсеш чараларында (өстәмә һөнәри белем бирүне кертеп) катнашучы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, җәмәгать судлары аппаратлары хезмәткәрләре өлеше | ДП | процент | 2 | 5 | 10 | 12 | 15 | 17 | 20 | 22 | 25 | 29 | 30 | 33 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.6. | Гавами хакимият органнарының төп игътибарны клиентларга бирүенә, дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең цифрлы, мәгълүмат-аналитика һәм коммуникатив күнекмәләре дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән компетенцияләрне үстерү блокларын үз эченә алган, гамәлгә ашырылган мәгариф программалары өлеше | ДП | процент | 0 | 5 | 10 | 15 | 20 | 25 | 30 | 35 | 40 | 50 | 55 | 65 |
| 1.7. | «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» конкурсын үткәрү | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.8. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эшләнгән Электрон мактау тактасы | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |
| 1.9. | Дәүләт органнарының гомуми санында һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә студентларны практикага (стажировкага) алган дәүләт органнары өлеше | ДП | процент | 5 | 10 | 15 | 20 | 30 | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | 100 |
| 1.10. | Яшьләр өчен дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсе, халыкның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегеннән канәгатьлелеге, шулай ук дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеге һәм абруе турында материаллар бирелгән статистика җыентыклары саны | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 1 |
| 1.11. | Социаль челтәрләрдә һәм башка заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларында урнаштырылган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне популярлаштыруга һәм аларның абруен күтәрүгә юнәлдерелгән материаллар саны | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 | 20 |
| 1.12. | Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт өлкәсендә законнарга үзгәрешләр кертү турында еллык хисап | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.13. | Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарны үтәү, дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында кадрлар эшен камилләштерү, персонал белән идарә итүнең заманча технологияләренә ориентацияләү буенча тикшерү чаралары саны | ДП | берәмлек | 0 | 0 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 0 | 8 |
| 1.14. | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълүматлар булу | ДП | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 1.15. | Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында, техник биремдә күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып, функционал артуга бәйле рәвештә кертелгән үзгәрешләр булу | ДП | процент | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 100 | 100 |

## 4. Татарстан Республикасы дәүләт программасы структурасы

| Т/с | Структур элемент бурычлары | Структур элемент бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрнең кыскача тасвирламасы | Күрсәткечләр белән бәйләнеш |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы | | | |
| «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләрне кертү» төбәк проекты | | | |
| | Гамәлгә ашыру өчен җаваплылар:<br>А.Н.Белов – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе (килешү буенча);<br>И.М.Гарипов – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча);<br>Р.И.Заһидуллин – Татарстан Республикасы юстиция министры;<br>М.Р.Шаһиәхмәтов – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – | Гамәлгә ашыру срогы: 2024 – 2026 еллар | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы икътисад министры;<br>А.Р.Хәйруллин – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры;<br>И.Г.Һадиуллин – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры;<br>Р.Н.Садыйков – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры;<br>А.С.Сәлимгәрәев – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе;<br>А.Н.Кудрявцева – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры;<br>И.А.Привалов – Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры (килешү буенча);<br>Ә.С.Гобәйдуллин – «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) | | |
| 1. | Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген (шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша) күтәрү | Дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вазыйфаларны нәтиҗәле үтәү | 1. Кадрлар эше нәтиҗәлелеген квартал саен мониторинглау нигезендә дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының формалаштырылган рейтингы.<br>2. Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре турында ел саен актуальләштерелгән хокукый актлары булу.<br>3. Муниципаль берәмлекләрнең гомуми санында дәүләт программасында билгеләнгән чорга муниципаль хезмәтне үстерү буенча муниципаль программалар расланган муниципаль берәмлекләр өлеше |
| 2. | Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы циклдагы белем бирү мохитен булдыру | Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары кадрлар составының һөнәри дәрәҗәсен өзлексез күтәрү, хезмәткәрләрнең шәхси һәм һөнәри потенциалын үстерү | 1. Һөнәри үсеш чараларында (өстәмә һөнәри белем бирүне кертеп) катнашучы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, җәмәгать судлары аппаратлары хезмәткәрләре өлеше.<br>2. Гавами хакимият органнарының төп игътибарны клиентларга бирүенә, дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең цифрлы, мәгълүмат-аналитика һәм коммуникатив күнекмәләре дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән компетенцияләрне үстерү блокларын үз эченә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | алган, гамәлгә ашырылган мәгариф программалары өлеше |
| 3. | Җәмәгать контроле системасын һәм граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүне үстерү, дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору буенча чараларны гамәлгә ашыру | Гражданнарның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә ышаныч дәрәҗәсен арттыру | 1. Яшьләр өчен дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсе, халыкның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегеннән канәгатьлелеге, шулай ук дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеге һәм абруе турында материаллар бирелгән статистика җыентыклары саны.<br>2. Социаль челтәрләрдә һәм башка заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларында урнаштырылган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне популярлаштыруга һәм аларның абруен күтәрүгә юнәлдерелгән материаллар саны |
| 4. | Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының хезмәт культурасын камилләштерү, дәүләт һәм муниципаль хезмәт системасында лидерлыкны һәм патриотизмны үстерү | Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт системасының тотрыклылыгын һәм бөтенлеген үстерү | Югары потенциалга һәм лидерлык сыйфатларына ия дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләргә ярдәм итү системасын формалаштыру<br>(шул исәптән аларны хезмәт буенча үстерү максатларында) |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне кадрлар белән тәэмин итүне камилләштерү» процессы чаралар комплексы | | | |
| | Гамәлгә ашыру өчен җаваплылар:<br>Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;<br>дәүләт органнары;<br>җирле үзидарә органнары (килешү буенча);<br>«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | Гамәлгә ашыру срогы: 01.01.2024 - 31.12.2026 | |
| 1. | Дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, аларның эшчәнлеген комплекслы бәяләүнең һәм аларны хезмәт буенча үстерүнең | 1. Дәүләт идарәсенең һәм муниципаль идарәнең югары нәтиҗәлелеген тәэмин итүче дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль | 1. Дәүләт органнарында структур бүлекчәләр җитәкчеләренең гомуми санында дәүләт органнарында кадрлар резервы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициативалы хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү | хезмәтнең кадрлар составын формалаштыру.<br>2. Нәтиҗәле хезмәткәрләрне хезмәт буенча үстерү.<br>3. Кадрлар резервларыннан нәтиҗәле файдалану | төзелгән (актуальләштерелгән) структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары өлеше.<br>2. Идарә кадрлары резервына кертелгән затлар саны.<br>3. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең идарә компетенцияләрен бәяләүне оештыру |
| 2. | Дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү | Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары кадрларының һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү.<br>Дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә югары квалификацияле кадрларны тоту | 1. «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» конкурсын үткәрү.<br>2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эшләнгән Электрон мактау тактасы |
| 3. | Һөнәри мотивлаштырылган яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәтнең абруен арттыру, уңайлы шартлар тудыру | Дәүләт органнарын һәм җирле үзидарә органнарын профессиональ кадрлар белән үз вакытында тәэмин итү.<br>Дәүләти граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә яшь белгечләрне җәлеп итү | Дәүләт органнарының гомуми санында һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә студентларны практикага (стажировкага) алган дәүләт органнары өлеше |
| 4. | Дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне норматив һәм методик тәэмин итү | Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча норматив хокукый базаны камилләштерү һәм актуальләштерү | 1. Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт өлкәсендә законнарга үзгәрешләр кертү турында еллык хисап.<br>2. Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарны үтәү, дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында кадрлар эшен камилләштерү, персонал белән идарә итүнең заманча технологияләренә ориентацияләү буенча тикшерү чаралары саны |
| 5. | Дәүләт хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмати-коммуникация технологияләрен куллану | Заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану исәбенә кадрлар эшенең сыйфатын яхшырту һәм нәтиҗәлелеген күтәрү | 1. Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълүматлар булу<br>.<br>2. Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында, техник биремдә күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып, функционал артуга бәйле рәвештә кертелгән үзгәрешләр булу |

## 5. Татарстан Республикасы дәүләт программасының финанс белән тәэмин ителеше

| Татарстан Республикасы дәүләт программасының, структур элементның исеме / финанс белән тәэмин итү чыганагы | Гамәлгә ашыру еллары буенча финанс белән тәэмин ителеш күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | барлыгы |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы – барлыгы, шул исәптән: | 35 585,0 | 35 585,0 | 35 585,0 | 106 755,0 |
| федераль бюджет | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 35 585,0 | 35 585,0 | 35 585,0 | 106 755,0 |
| бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| бюджеттан тыш чыганаклар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру» төбәк проекты. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү – барлыгы, шул исәптән: | 35 585,0 | 34 803,8 | 35 585,0 | 105 973,8 |
| федераль бюджет | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 35 585,0 | 34 803,8 | 35 585,0 | 105 973,8 |
| бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| бюджеттан тыш чыганаклар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне кадрлар белән тәэмин итүне камилләштерү» процессы чаралар комплексы – барлыгы, шул исәптән: | 0,0 | 781,2 | 0,0 | 781,2 |
| федераль бюджет | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 0,0 | 781,2 | 0,0 | 781,2 |
| бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| бюджеттан тыш чыганаклар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |